# КАРАР

**03 декабрь, 2019 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019елның 28 ноябрендә хэм 02 декабрендэ түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары һәм шулай ук 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Пчеловод авылы урам яктырткычлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;
- Пчеловод авылына насослары сатып алу
- чишмәне төзекләндерү (койма буяу, тротуар плиткасы җәю, буталы божра урнаштыру).;
- Пчеловод авылы зиратын коймалау өчен материал сатып алу;
- Пчеловод авылында юлларны кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Пчеловод авылында янгын сулыгын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- 2 шт. күләмендә Пчеловод авылынын Центральная урамы буенча торба сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 218 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 122 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 122 кеше тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары һәм шулай ук 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:
- Пчеловод авылы урам яктырткычлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;
- Пчеловод авылына насослары сатып алу
- чишмәне төзекләндерү (койма буяу, тротуар плиткасы җәю, буталы бөҗра урнаштыру).;
- Пчеловод авылы зиратын коймалау өчен материал сатып алу;;
- Пчеловод авылында юлларны кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Пчеловод авылында янгын сулыгын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- 2 шт. күләмендә Пчеловод авылында Центральная урамы буенча торба сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»
кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары Чура авыл җирлеге

башлыгы урынбасары: А.Н. Афанасьев